## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлегенең Түбән Кенә авылы Халык җыены нәтиҗәләре турында**

2020 ел 23 октябрь

№ 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 23 октябрендәузган гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә беркетмә төзелде.; Яңа урам юлларын төзекләндергәннән соң, Ю.Гагарин урамында янгынга каршы гидрант һәм аңа комплектлау әйберләре сатып алып урнаштырганнан соң экономияләнгән 43774,33 (кырык өч мең җиде йөз җитмеш дүрт) сум 33 тиен күләмендә гражданнарның үзара салым акчаларын:

- Яңа, Ю. Гагарин, Мәктәп, Тауасты, Яшель, Бакый Рәхимов урамнарындагы юлларны ремонтлау белән бәйле юл катламын грейдерлау өчен - 43774,33 (кырык өч йөз җитмеш дүрт) сум 33 тиен – файдаланырга риза буласызмы.

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
Җыенда сайлау хокукына ия булган 235 кешенең, 147 кеше тавыш бирүдә катнашкан. Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен җыенда 147 кеше тавыш бирде;
«юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.
Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Түбән Карадуган авыл җирлегенең Түбән Кенә авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.
2. " Яңа урам юлларын төзекләндергәннән соң, Ю.Гагарин урамында янгынга каршы гидрант һәм аңа комплектлау әйберләре сатып алып урнаштырганнан соң экономияләнгән 43774,33 (кырык өч мең җиде йөз җитмеш дүрт) сум 33 тиен күләмендә гражданнарның үзара салым акчаларын:

- Яңа, Ю. Гагарин, Мәктәп, Тауасты, Яшель, Бакый Рәхимов урамнарындагы юлларны ремонтлау белән бәйле юл катламын грейдерлау өчен - 43774,33 (кырык өч йөз җитмеш дүрт) сум 33 тиен – файдаланырга-кабул ителгән дип исәпләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы pravo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматының рәсми порталында халыкка игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче:
Балтач муниципаль районы
Карадуган авыл җирлеге башлыгы: Ш. В. Низамиев